**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ШЕТНЕВО-ТУЛУШСКОГО**
**сельского поселения**
**Рыбно-Слободского**
**муниципального района**
**422644, с.Шетнево-Тулуши**
ул.М.Джалиля, д.18,

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**ЮГАРЫ ЫРГА авыл җирлегенең**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**422644, Шетнево-Тулуш,**
М.Җәлил урамы, 18.

Тел.: (884 361) 27-451, факс: (884 361) 27-451. электронный адресl: **Stul.Rs@tatar.ru**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31 гыйнвар, 2022 ел Югары Ырга авылы №3

Мәет җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, “Мәет кую һәм җирләү эше турында” 12.01.1996 ел, № 8-ФЗ Федераль закон, “Татарстан Республикасында мәет кую һәм җирләү эше турында”гы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Югары Ырга авыл җирлегендә мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымтага ярашлы рәвештә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы 29.01.2021 елның № 1 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 йорт; Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 йорт; Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырылган: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Багаутдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Зур Мәшләкавыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына кушымта

**2022 елның 1 февраленнән мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табут һәм җирләү өчен зарур булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китерү | 2646,95 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (мәетне) зиратка алып бару (илтү) | 997,28 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җиргә иңдерү) | 3320,45 |
| БАРЫСЫ | 6964,68 |

**2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлегендә мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә хатыны (ире), якын туганнары, башка туганнары яки мәрхүмнең законлы вәкиле булмаса яисә алар тарафыннан мәетне җирләү мөмкин булмаганда яки мәрхүмне соңгы юлга озату бурычын үз өстенә алучы башка зат табылмаганда түләүсез нигездә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кәфенләү | 500,00 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен зарур булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китерү | 2146,95 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (мәетне) | 997,28 |

| | |
|---|---|
| зиратка алып бару (илтү) | |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм җиргә иңдерү) | 3320,45 |
| БАРЫСЫ | 6964,68 |